| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
|---|---|---|
| 14 декабрь, 2016 | Казан шәһәре | № 93 |

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч түләвенә ышанычсыз дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымталарда бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул итү тәртибен;

бюджет керемнәре администраторы хисапларыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларына түләүләрне түләү буенча исәпкә алына торган бурыч суммалары хакында өземтә рәвешен;

бөлгенлек турында эш буенча эш кузгату өчен нигезләр юклыгы турында белешмә рәвешен.

2. Инспекциянең структур бүлекчәләре җитәкчеләренә шушы боерыкны Инспекциядәге вазыйфаи затларга җиткерергә.

3. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкчесе В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең 2016 елның 14 декабрендәге 93 номерлы боерыгы белән расланган

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ БЮДЖЕТ СИСТЕМАСЫ БЮДЖЕТЛАРЫНА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТҮГӘ ЫШАНЫЧ ЮКЛЫГЫН ТАНУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТҮ ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына керемнәрнең баш администраторы буларак Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели.

2. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә түбәндәге очракларда шаныч юк дип танылa:

1) физик зат – Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр түләүче вафат булганда яисә Россия Федерациясенең граждани-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгәндә;

2) шәхси эшкуар – Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр түләүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча әҗәт түләүченең мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле түләнмәгән бурычы өлешендә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип танылганда;

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яисә) күрсәтелгән оешманы гамәлгә куючыларның (анда катнашучыларның) аларны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле түләнмәгән бурычы өлешендә оешма – Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр түләүче бетерелгәндә;

4) түләттерүнең билгеләнгән вакыты (дәгъва белдерү чоры) узып китүгә бәйле рәвештә, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерү турында судка гариза тапшыруның узып киткән вакытын торгызудан баш тарту турында суд билгеләмәсе чыгарылуга бәйле рәвештә, суд тарафыннан Инспекциянең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген юкка чыгара торган акт кабул ителгәндә;

5) суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларда каралган нигезләр буенча башкару эшенең тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр дә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:

- бурыч күләме бурычлы затка карата банкротлык турында эш кузгату өчен Россия Федерациясенең бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш туктатылганда;

6) административ штрафлар билгеләнгән вакытта түләнмәгәндә һәм Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексында билгеләнгән административ җәза билгеләү турында карарны үтәүнең дәгъва бирү вакыты узганда, мондый вакытка тәнәфес ясау,

туктатып тору яисә аны озынайту өчен нигезләр булмаган очракта.

3. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

1) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыкка килүне раслый торган документлар;

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Инспекция хисапнамәсеннән өземтәләр (әлеге Боерыкка 2 нче кушымта);

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерелүен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында, раслый торган документларны теркәп, Инспекция белешмәләре;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерүгә ышанычсыз булуын тануның әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән очракларын раслый торган документлар:

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

физик зат – түләүченең вафат булуын таныклый торган яисә аның вафат дип игълан ителүе турында дәлилләүче документ (күчермәсе);

шушы Тәртипнең 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар реестрыннан шәхси эшкуарның – бюджетка түләүләр түләүченең банкрот дип танылуына бәйле рәвештә эшчәнлеге туктатылу турындагы белешмәләрне үз эченә ала торган документ;

шушы Тәртипнең 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

Бердәй дәүләт юридик затлар реестрыннан оешманың – бюджетка түләүләр түләүченең бетерелүенә бәйле рәвештә эшчәнлеге туктатылуы турындагы белешмәләрне үз эченә ала торган документ;

шушы Тәртипнең 1 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

түләттерүнең билгеләнгән вакыты (дәгъва белдерү чоры) узып китүгә бәйле рәвештә, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерү турында судка гариза тапшыруның узып киткән вакытын торгызудан баш тарту турында суд билгеләмәсе чыгарылуга бәйле рәвештә, бюджет керемнәре администраторының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген юкка чыгара торган, законлы көченә кергән суд актының күчермәсе;

Шушы Тәртипнең 1 пунктындагы 5 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

«Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 елешендәге 3 һәм 4 пунктларда каралган нигезләр буенча суд приставы-башкаручының башкару эшенең тәмамлануы һәм башкару документларының түләттерүчегә кайтарып бирелүе турындагы карары күчермәсе;

банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен нигезләр булмау турында белешмәләр (әлеге Боерыкка 3 нче кушымта);

бурычлы затны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтарып бирү турында яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрү өчен суд чыгымнарын түләү өчен җитәрлек дәрәҗәдә акча булмауга бәйле рәвештә банкротлык турындагы эшнең туктатылуы турында суд билгеләмәсе күчермәсе (әгәр бурыч күләме банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен Россия Федерациясенең бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китсә);

шушы Тәртипнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

«Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 47 статьясының 1 өлешендәге 9 пунктында каралган нигезләр буенча суд приставы-башкаручының башкару эшенең тәмамлануы турында карары күчермәсе, яисә Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 31.7 статьясының 4 пунктында каралаган нигезләр буенча административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүдән туктау турында карар күчермәсе.

4. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләп бетерүгә ышанычсыз дип тану турындагы карар даими эшләүче комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан кабул ителә, аның составы начальник приказы белән раслана.

5. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча түләтү өчен ышанычсыз дип танылырга тиешле бурычның булуы турында мәгълүмат, Тәртипнең 2 пунктындагы 1, 3, 4 пунктчаларында каралган документларны теркәп, Комиссиягә Инспекциянең административ тәҗрибә һәм өлешле төзелешне тикшереп тору бүлеге, юридик бүлеге, территориаль органнары тарафыннан җибәрелә.

6. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләттерелүен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Инспекция белешмәләре Комиссиягә бюджет керемнәре администраторы административ тәҗрибә һәм өлешле төзелешне тикшереп тору бүлеге, юридик бүлеге, территориаль органнары тарафыннан җибәрелә.

7. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Инспекция хисапнамәсеннән өземтәләр Комиссиягә Инспекциянең финанс-икътисад контроле бүлеге тарафыннан җибәрелә.

8. Комиссия Инспекциянең структур бүлекчәләреннән шушы Тәртипнең 4, 5, 6 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар һәм документлар кергәндә зарурлык булу дәрәҗәсенә карап утырышлар үткәрә.

9. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар Комиссия тарафыннан Комиссия утырышы үткәрелгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

10. Әгәр дә Комиссия утырышында аның барлык әгъзалары да катнашса, Комиссия карары тулы хокуклы дип санала.

11. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

12. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында бәяләмә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) оешма - бурычлы затның тулысынча аталышы (физик зат - бурычлы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме);

2) салым түләүченең индентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, физик затның салым түләүченең идентификацияләү номеры;

3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәрен классификацияләү коды, аның аталышы;

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның суммасы;

5) Комиссия әгъзаларының имзалары;

6) бурыч барлыкка килгән түләү турында белешмәләр;

7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул ителү көне.

13. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында Комиссия карары Инспекция башлыгы тарафыннан раслана.

14. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында Комиссия карары бурычны бюджет системасыннан (бухгалтерлык исәбеннән) һәм Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы) алу (торгызу) өчен нигез булып тора.

ТР ДТК инспекциясенең 2016 елның 14 декабрендәге 93 номерлы боерыгы белән расланган

Үрнәк

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның исәпкә алына торган суммалары турында бюджет керемнәренең баш администраторы буларак Инспекция хисапнамәсеннән 20__елның «__»______ №___ өземтә

| т/с | Керемнәрнең бюджет классификациясе коды | Бурычлының аталышы | Бурыч хасил булган дата | Документ-нигезләүнең реквизитлары | | | Бурыч суммасы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Атамасы | Дата | № | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | Җәмгысе: | | | | | | |

Финанс-икътисадый контроль бүлеге җитәкчесе урынбасары
____________/___________________/
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

ТР ДТК инспекциясенең 2016 елның 14 декабрендәге 93 номерлы боерыгы белән расланган

Форма

Банкротлык эше буенча эш кузгату өчен нигезләр булмавы турында
белешмә

Дата

«Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларда каралган нигезләр буенча _______________ карата ___________ №___ эш буенча башкару эшенең төгәлләнүе турында пристав-башкаручы тарафыннан карар чыгарылуга бәйле рәвештә, Хокук идарәсе тарафыннан _______________________________________________________________________ карата банкротлык эше буенча эш кузгату турындагы мәсьәлә карап тикшерелде.

____________ № _____ административ хокук бозу эше турындагы карар буенча бурыч күләме ___________ сум тәшкил иткәнгә күрә һәм банкротлык эше буенча эш кузгату өчен бурычлы затка карата Россия Федерациясенең бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәвенә бәйле рәвештә, _______________ карата банкротлык турында эш кузгату өчен нигезләр юк.

____________ №____ административ хокук бозу эше турындагы карар буенча _________________ күләмендәге ______________ бурыч, ___________ бурыч барлыкка килү датасыннан башлап биш ел узгач, түләттерү өчен ышанычсыз дип танылырга мөмкин.

Вазыйфа ________________________/________________/
(Ф.И.А.) (имза)